СОВЕТ
ВВЕДЕНСКО-СЛОБОДСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ВВЕДЕНСКИЙ БИСТӘСЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ | КАРАР

16.04.2021 | с. Введенская Слобода | №8-42

Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлегенең
2021нче елның 1нче кварталы өчен бюджеты үтәлеше турында
отчетны раслау турында

Введенский Бистәсе авыл җирлеге башлыгы Д. В. Морозовның Введенский Бистәсе авыл җирлеге бюджетының 2021нче елның 1нче кварталында үтәлеше турында хисабын тыңлап фикер алышкннан соң ,

Югары Ослан муниципаль районы
Введенский Бистәсе авыл җирлеге Советы
Карар итте:

1. Введенский Бистәсе авыл җирлеге бюджетының 2021нче елның 1нче кварталы өчен үтәлеше турында отчетны расларга (1нче кушымта)
2. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.
3. Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлеге Советының бюджет-финанс һәм икътисад мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны йөкләргә.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Введенский Бистәсе авыл җирлеге башлыгы Д. В. Морозов

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Введенский Бистәсе авыл җирлеге
Советының 2021нче елның
16нчы апрелennән 8-42нче
номерлы карарына
1нче кушымта

«Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлегенең 2021нче елның 1нче кварталы өчен бюджет үтәлеше турында хисап»

Введенский Бистәсе авыл җирлеге бюджетының 2021нче елда үтәлеше «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003нче елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законны алып бару һәм тормышка ашыру шартларында тормышка ашырыла.

Введенский Бистәсе авыл җирлеге бюджеты, үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертеп, керемнәр буенча 9896,2 мең сум күләмендә расланган.

Авыл җирлегенең 2021нче елның 31нче мартына керем өлеше буенча 1579,1 мең сум, үтәлеш 16% үтәлгән.

Җирлек бюджеты керемнәренең төп өлеше түбәндәге салымнар хисабына формалашты:

- физик затлар кеременә салым 97 % үтәлгән (план 1000,1 мең сум булганда 969,7 мең сум үтәлгән);
- физик затлар милкенә салым - 8,7% (70,5 мең сум үтәлгән, план 812,1 мең сум тәшкил итә);
- җир салымы - 5,7 % үтәлгән (план буенча 7819 мең сум), шулардан 364,8 мең сум - оешмалар һәм 78,3 мең сум - халыктан.
- мөлкәтне арендага бирүдән кергән табыш – 1,2 мең сум;
- түләүле хезмәтләр күрсәтүдән керем - 41,7 мең сум;
- бердәм авыл хуҗалыгы салымы - 10,9 мең сум;
- үзара салым – 42 мең сум.

Бюджетның төгәлләштерелгән чыгым өлеше 11004,7 мең сум тәшкил итте, фактта чыгым 1060,7 мең сум күләмендә үтәлде һәм 10% үтәлде.
Акча тотылды:
- идарәгә 285,97 мең сум - яки 21,1 %;
- мәдәният 105,5 мең сум – 16,6%;
- төзекләндерү - барлыгы 379,5 мең сум – 24, 1%, шулардан урам яктылыгына 134,6 мең сум – 25,68 % - юлларны карап тотуга - 244,8 мең сум - 30%.
Коммуналь хуҗалык өлкәсендәге чараларга (шул исәптән су кудыргычлар) 581,2 мең сумнан 200,8 мең сум тотылган, ягъни 35%.
Бюджетара трансферлар 6760,9 мең сум күләмендә планлаштырылган, фактта 64 мең сум тотылган.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Введенский Бистәсе авыл җирлеге башлыгы Д. В. Морозов